**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2024 елның 27 ноябрендәге 4893 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 9 сентябрендәге 3778 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты каршындагы муниципаль ихтыяҗлар өчен товарларны, эшләр башкаруны, хезмәтләр күрсәтүне сатып алу мәсьәләләре буенча иҗтимагый совет турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтүне сатып алу мәсьәләләре буенча иҗтимагый совет составы үзгәрүгә бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 9 сентябрендәге 3778 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты каршындагы муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтүне сатып алу мәсьәләләре иҗтимагый советы турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 30 июнендәге 1604 номерлы, 2023 елның 3 апрелендәге 987 номерлы, 2023 елның 8 августындагы 2238 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 номерлы кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. әлеге карар кушымтасын Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 9 сентябрендәге 3778 номерлы карарының 2 номерлы кушымтасы дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 27 ноябрендәге
4893 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитеты каршындагы
муниципаль ихтыяҗлар өчен товарларны, эшләр башкаруны,
хезмәтләр күрсәтүне сатып алу мәсьәләләре буенча
иҗтимагый совет составы**

Совет әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Мөдәррисов Равил Миңнесалих улы | «Казан шәһәренең конкурентлык сәясәте һәм сатып алулар дирекциясе» муниципаль казна учреждениесе директоры |
| Мерзлякова Татьяна Сергеевна | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының социаль мәсьәләләр, хәйриячелек һәм коммерцияле булмаган секторны үстерү комиссиясе рәисе урынбасары, «Игелекле Казан» автоном коммерцияле булмаган оешмасы директоры (килешү буенча) |
| Бәширов Радик Рузлан улы | «“ФСК Регион” техник заказчысы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең беренчел-рөхсәт документлары буенча баш инженеры (килешү буенча) |
| Шәйхетдинова Эльмира Рамазан кызы | «Казан шәһәре конкурентлык сәясәте һәм сатып алулар дирекциясе» муниципаль казна учреждениесенең юридик һәм оештыру-кадрлар эше бүлеге башлыгы |
| Лотфуллина Алия Фәнис кызы | «Энергогрупп» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Савенков Сергей Николаевич | «Совкомбанк» гавами акционерлык җәмгыятенең челтәрне инспекцияләү бүлеге инспекторы (килешү буенча) |